## Мин татар телен ничек өйрәнәм

Татар теле - Татарстанның дәүләт теле, таралышы буенча Россиядә икенче тел. ЮНЕСКО игълан иткән 14 иң коммуникатив тел исемлегенә керә. Татар теле бик кызыклы тел, шуңа күрә без 37 нче урта мәктәбе укучылары, аны бик яратып өйрәнәбез. Укытучыларыбыз татар теле дәресләрен төрле-төрле алымнар белән алып баралар: уен формалары, кроссвордлар, татар телендә газеталар уку һәм башкалар. Шулай ук без дәресләрдән тыш чараларда актив катнашабыз. Ел саен уза торган “Диалог”, “Мин татарча сөйләшәм” һәм башка республикакүләм конкурсларда катнашабыз.

XXI гасыр интернет чоры булгач, интернет аша теләсә нинди мәгълүматны алып була. Телләрне дә интернет аша өйрәнү мөмкин. Интернет челтәрендә махсус сайтлар җитәрлек.

1. «Ана теле»онлайн мәктәбе.  Дөньякүләм English First оешмасы белән Татарстан хөкүмәте килешүе нигезендә эшләнгән бу сайтта татар телен бөтенләй белмәгән кешеләр дә өйрәнә ала. 9 тел белү дәрәҗәсе каралган, һәр дәрәҗәдә 8 комплексны дәрес бар.
2. «Татар теле баскычлары»сайты. Мәскәү егете Марат Төхвәтуллин ачып җибәргән бу сайтта татар теленең нигезләрен, грамматик төзелешен аңларга мөмкин. Ул Русия телевидениесенең “Полиглот” тапшыру методикасына охшатып төзелде. Сайтта виджетлар уңышлы ясалган, татар телен уен форматында өйрәнү мөмкин.
3. «Татар телен өйрәнү өчен« сайты. Рус телле укучыларга юнәлгән бу ресурста татар телен өйрәнүгә күпсанлы материаллар тупланган. Сүзлекләр, тәрҗемәчеләр, аудиокурс һәм үзөйрәткечләр – боларны бу сайттан алып өйрәнеп була. Моннан тыш, татар теле турында файдалы мәгълүматлар да тупланган.
4. ТНВ видеодәресләре. Татар телен укытуда бердәнбер зур видеодәрес курсы булып тора. Youtube-та урнаштырылган берничә йөз дәрестә төрле темаларга караган татар сүзләре белән танышырга мөмкин.
5. Вконтакте челтәрендә татар телен өйрәнүгә багышланган дистәләп төркем-паблик бар. Алар арасында иң зуры – Учим татарский язык! дигән паблик. Рәсемнәр, юмор, аудио-видео һ.б. аша көндәлек татар телен укыту эше бара биредә. Пабликка 57 меңнән артык кеше язылган.

Хәзерге көндә дәрестәш чараларның бик актуаль төре – проект эшләре башкару. Без шулай ук татар теленнән дә бик кызыклы проект эшләре башкарабыз. Мәсәлән, узган уку елында “Татарстан Республикасы буенча сәяхәт” исемле уен ясадык. Әлеге проек эшенең максаты – төрле милләт вәкилләре арасында татар теленә карата кызыксыну булдыру, шуның аркылы телне саклап калу.

Тагын бер зур проект эше Яр Чаллы шәһәре буенча ясалган юлнамә. Шушы басмада шәһәребездә урнашкан барлык истәлекле, күңел ачу, мәдәният урыннарының характеристикасы, адреслары, телефон номерлары тупланган. Әлеге мәгълүмат юлнамәдә татар, рус һәм инглиз телләрендә бирелгән.

Шулай итеп, татар телен өйрәнү өчен күптөрле юллар бар: мәктәптәге дәресләр, дәрестән тыш чаралар, интернет челтәре. Татар телен без рәхәтләнеп өйрәнәбез сезгә дә тәкъдим итәбез!

ШКОЛА 37

Школьная газета «Esprit»
МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №37 с углубленным изучением отдельных предметов»
Адрес: 423826, республика Татарстан,
г. Набережные Челны, Новый город,
пр. Сююмбике, д.103 (51/12)
телефон: +7(855)-242-56-25
E-mail: S37.Nc@tatar.ru, sch37_chelny@mail.ru

ШКОЛА 37

# Esprit

Школьная газета, январь 2021



2021 Год родных языков и народного единства

Январские новости

Доска почёта, или лучшие из лучших

Как сдать итоговое собеседование. Советы экспертов

План мероприятий по проведению Года родных языков и народного единства

2021 — туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы

Гыйнвар яңалыклары

Почет тактасы, яки яхшылардан яхшылар

Йомгаклау киңәшмәсенә ничек әзерләнергә

Экспертлар киңәше

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге Елын үткәрү буенча чаралар планы

# 2021 Год родных языков и народного единства



В РТ 2021 год объявлен годом родных языков и народного единства
Ранее эту идею Рустам Минниханов озвучил в рамках послания к Госсовету.

2021 год в РТ объявлен Годом родных языков и народного единства. Соответствующий указ подписан президентом республики.

Ранее эту идею Рустам Минниханов высказал в рамках послания к Госсовету РТ: «Мы должны создавать условия для сохранения всех языков и культур народов, проживающих в республике», — отметил он.

## К сведению

**Красочной концертной программой мастеров искусств республики был дан старт Году родных языков и народного единства в Ассамблее народов Татарстана.**

Высокую оценку Фарид Мухаметшин дал и деятельности Ассамблеи народов Татарстана: «За почти три десятилетия активной деятельности Ассамблея стала авторитетным общественным институтом, настоящим центром консолидации многонационального движения народов Татарстана, объединила под своим крылом около 240 национально-культурных объединений (28 региональных и 210 местных). Под эгидой Ассамблеи эффективно работают восемь Домов и четыре Центра дружбы в Казани, Набережных Челнах, Нижнекамске, Менделеевске, Тетюшах, Нурлате, Лениногорске и Азнакаеве.

В районах республики успешно функционируют два филиала и уже 24 представительства Ассамблеи.

В конце прошлого года открыты еще 5 представительств в Аксубаевском, Бавлинском, Заинском, Кайбицком и Пестречинском муниципальных районах».

Визитной карточкой республики, по словам Фарида Мухаметшина, стали народные праздники и фестивали – Сабантуй, Каравон, Уяв, Семык, Гырон быдтон, Навруз и многие другие. «Отрадно, что идейными вдохновителями здесь выступают сами национально-культурные автономии», – подчеркнул глава парламента.



## А вы знали, что...

Большую роль в сохранении родных языков играют образовательные программы. В Татарстане сегодня работает 871 образовательная организация с русским языком обучения, 657 – с татарским. 132 школы с этнокультурным компонентом (чувашский – 88 школ, удмуртский – 24, марийский – 16, мордовский – 3, одна школа с изучением иврита). В 22 отделениях Многонациональной воскресной школы изучают язык и культуру 19 национальностей.

**Году родных языков и народного единства в этом году будут посвящены и парламентские уроки, которые пройдут во всех школах республики с 15 по 20 февраля.**



***«Год родных языков и народного единства у нас начался не первого январяи, думаю, не закончится 31 декабря, поскольку специфика межэтнических и межконфессиональных отношений состоит в том, что они не имеют конечного решения и требуют постоянного внимания», – заключил Фарид Мухаметшин.***

## У нас, в 37-ой

23 января 2021 г. в нашей школе прошло мероприятие, посвященное торжественному открытию Года родных языков и народного единства.В концерте приняли участие учащиеся 5-11 классов с номерами, посвященными дню родных языков. Кроме того, библиотекарем, Нурлыгаяновой А.М., была организована выставка, на которой были представлены различные произведения авторов разных народов.

Администрация школы выражает огромную благодарность классным руководителям и Динаре Гилмановне за подготовку и проведение концерта.

**ПЛАН**
**мероприятий по проведению в Республике Татарстан**
**Года родных языков и народного единства**
**МБОУ «СОШ №37 с углубленным изучением отдельных предметов**

| № | Наименование мероприятия | Дата проведения |
|---|---|---|
| 1 | Оформление информационных стендов “Как славно ты звенишь, родной язык”. | январь |
| 2 | Беседа “Мой родной верный друг – родной язык». | январь |
| 3 | Анкетирование «Народные традиции в вашей семье». | |
| 4 | Конкурс юных чтецов «Живая классика»<br>Беседа о М.Джалиле. | февраль |
| 5 | Беседа « Международный день родного языка». | февраль |
| 6 | Книжные выставки, обзоры литературы “И туган тел...”, “День родного языка”. | февраль |
| 7 | КВН “Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел”. | февраль |
| 8 | Организация книжных выставок и тематических подборок детской литературы. | март |
| 9 | Организация и проведение акции «Родной язык- 2021» | март |
| 10 | Конкурс рисунков «Тарих эзләреннән» | март |
| 11 | Творческий конкурс, посвященный дню рождения Г.Тукая, «Куллар тудырган могҗиза» | апрель |
| 12 | Просмотр м/ф на татарском языке | апрель |
| 13 | Праздник поэзии, посвященный Дню родного языка и дню рождения Г.Тукая | апрель |
| 14 | Возложение цветов к памятнику Г.Тукаю | апрель |
| 15 | Акция «Мин татарча сөйләшәм!» | май |
| 16 | Литературный марафон “Туган телем – татар телем!” | май |

# Основное в январе



27 января в школе для учеников 1-11 классов прошли классные часы и внеклассные мероприятия, посвященные Дню снятия блокады Ленинграда.В конце классных часов ребята почтили память жертв блокадного Ленинграда минутой молчания.




В условиях непростого времени, в условии пандемии, администрацией школы было принято решение поддержать многодетные семьи и семьи, где есть дети-инвалиды. В связи с этим директор школы вручила продуктовые наборы активистам, учащимся школы из данных семей и пожелала детям хорошей учебы и дальнейшего активного участия в общественной жизни класса и школы.



22 января в детско-юношеской спортивной школе «Этюд» прошли соревнования по шахматам среди работников образования города.

В интеллектуальной игре приняли участие 156 человек из 117 образовательных учреждений. Турнир проходил по швейцарской системе, где победители определяются по наибольшему количеству очков предварительных и финальных игр. Благодарим за участие Коловского Артура Андреевича и Халиуллину Гульназ Васимовну.



На зимних каникулах учителями МБОУ СОШ №37 были организованы лыжные гонки на приз Деда Мороза. Мероприятие проходило на территории школы. В состязаниях приняли участие ученики 1-4 классов.

# Лучшие из лучших



Поздравляем команду школы во главе с Еленой Николаевной Варламовой за результативное участие в региональном этапе Всероссийской олимпиады школьников по французскому языку! Желаем удачи и дальнейших высоких побед!



На зимних каникулах учащиеся со своими классными руководителями приняли участие в различных мероприятиях: посетили картинные галереи, музеи, библиотеки, театр. И, конечно же, не остались в без внимания как городские катки, так и каток нашей школы.




# Доска почёта


Уважаемая Елена Николаевна! Поздравляем Вас с достойной заслуженной победой учащихся на региональном этапе Всероссийской олимпиады школьников! Выражаем слова признательности и благодарности за столь яркие достижения. Гордимся Вами! Желаем дальнейших творческих успехов , счастья, здоровья, благополучия. Оставайтесь всегда такой же органичной и неповторимой в любом формате!

—





Администрация школы и педагогический коллектив благодарит Лёвину Алису Маратовну, учителя физической культуры, принявшую активное участие и достойно представившую школу в муниципальном этапе всероссийского конкурса «Учитель года-2021» в номинации «Педагогический дебют». Желаем дальнейших творческих успехов, крепкого здоровья, счастья, семейного благополучия!




Поздравляем учителей родного (татарского) языка и литературы Биккинину Э.М. ,
Назмутдинову Э.Ф.
Сафину Л.Р. - лидеров по результатам муниципального этапа Республиканской олимпиады школьников по родному (татарскому ) языку и литературе. Учитель Биккинина Э.М подготовила 6 призеров (5-родной( татарский)языка и 1 татарская литеература);
Назмутдинова Э. Ф. - 3 призера (2 по родному ( татарскому ) языку, 1 по татарской литературе);
Сафина Л.Р. -1 призёр по родному (татарскому ) языку. Данные учителя проявили инициативность, высокую компетентность, способность быстро и правильно приобретать необходимые навыки и умения
Уважаемые Эльвина Миргазиановна, Эльмира Факилевна, Лилия Рашитовна! Благодарим Вас за ежедневный кропотливый труд, выражаем признательность и восхищение за достигнутые феноменальные результаты. Желаем Вам новых профессиональных успехов , крепкого здоровья и благополучия! Будьте счастливы!

Поздравляем учителей школы, подготовивших победителей и призёров Всероссийской научно- практической конференции «На крыле науки»!
Пахомову Елену Витальевну,начальные классы,
Мешковец Ольгу Алексеевну, начальные классы,
Логачёву Елену Сергеевну, начальные классы,
Биккинину Эльвину Миргазиановну, (родной (татарский) язык и литература,
Сафину Лилию Рашитовну, родной (татарский) язык и литература,
Назмутдинову Эльмиру Факилевну, родной (татарский ) язык и литература,
Хуснуллину Гузель Агзамнуровну , математика

# Как сдать итоговое собеседование в 9 классе: советы экспертов ОГЭ

## Секреты выполнения заданий и чего нельзя делать на экзамене

***Как оценивается экзамен? Можно его пересдать?***

Нужно ответить на «зачет», то есть получить хотя бы 10 баллов по 20-ти критериям оценивания. Возможно, для кого-то набрать необходимую половину баллов с первого раза будет затруднительно, но шанс изменить результат будет. В случае провала, неявки по уважительной причине или невозможности завершить экзамен по уважительной причине школьникам предложат две пересдачи весной.

***Как проходит собеседование?***

Собеседование проводится в той школе, где вы учитесь или к которой вы прикреплены. Экзамен проходит по принципу «Микрофон — собеседник — я». Собеседник, который, по замыслу организаторов, должен создавать доброжелательную обстановку, общается со школьником. Эксперт молча делает свою работу, его не нужно бояться.

***Что можно и чего нельзя брать с собой?***

Только ручку. Всё остальное: тетради, словари, перекус, — в кабинет приносить нельзя.

***Какие проблемы могут возникнуть на собеседовании?***

Итоговое собеседование — экзамен устный, поэтому большинство проблем связано с неподготовленностью к устному общению. Многие ребята «бубнят под нос», отвечают односложно, просто теряются и замолкают. Кто-то может заплакать. Старайтесь не делать этого — вас записывают!

Говорите хоть что-то, вам поможет экзаменатор. У него есть целый список наводящих вопросов. А самое главное — никогда не произносите в микрофон фразы, типа «у меня нет слов», «я закончил ответ». Получается нелепо, как на физкультуре: «Расчет окончен». Ну и, конечно, не рассказывайте о личном — этого не нужно.

Основная проблема собеседования — влияние непривычной обстановки. Современным детям не так часто приходится отвечать устно перед «комиссией», которая еще и записывает ответ ученика на диктофон, иногда даже два раза. Хорошо подготовленным старшеклассникам все эти задания кажутся подозрительно простыми, но ребята с низким уровнем подготовки думают, что они сложные и непонятные. И само это страшное слово — «экзамен»...

Рецепт для того, чтобы избавиться от паники, про  стой. Напомните себе, что этот экзамен по уровню сложности недалеко ушел от заданий для 5-6 класса. А еще — что в случае провала у вас есть ещё две попытки. Настоящие экзамены у вас пока только впереди, это просто маленькая тренировка.

***Как дополнительно подготовиться к собеседованию за оставшееся время?***

Некоторые секреты подготовки к собеседованию приведены в повести «Время всегда хорошее» Андрея Жвалевского и Евгении Пастернак. Герои этой книги поняли, что лучший способ подготовки — не ждать дополнительных заданий от учителя, а тренироваться, чтобы проработать базовые навыки и снизить уровень тревожности. Для этого нужно:

- не стесняться устного общения,
- разговаривать друг с другом на разные темы «полными предложениями», без подсчета предложений и без «ну-у», «э-э», «короче», «типа»,
- играть в устные языковые игры (помните, из детства: «Я знаю пять имён мальчиков», «Да и нет не говорить»).

Мы посоветуем почитать вслух орфоэпический словарь школьника.

ESPRIT. Школьная газета, январь 2021

Да, это скучно, но это пригодится вам даже на ЕГЭ. варианты собеседования на сайте ФИПИ

Также нужно найти и проработать со взрослыми (с учителем или с родителями) тренировочные

А еще полезно вспомнить основные правила этикета — первый балл на этом экзамене можно потерять просто за то, как именно школьник поздоровался с экзаменаторами.

Возьмите любую понравившуюся вам картину или фотографию и попробуйте рассказать о ней родителям, другу или просто так, вслух. Говорите обо всем, что видите на ней. Попробуйте записать себя на диктофон. Посчитайте — должно быть не менее 10 фраз. Если получилось, вы на верном пути!

Не злитесь и не выказывайте эмоций: экзаменатор ни в чем не виноват, а звук записывается в течение всего экзамена. И не волнуйтесь: 10 баллов набрать нетрудно. У вас обязательно все получится! Великий академик Д.С. Лихачев однажды сказал: «Чтобы научиться ездить на велосипеде, надо ездить на велосипеде. Чтобы научиться писать, надо писать!» А мы добавим от себя: чтобы сдать итоговое собеседование — надо внимательно прочитать рекомендации и поменьше волноваться!

***Как выполнить задания***
***Задание № 1: чтение***

Тексты, предлагаемые на собеседовании, по мысли ФИПИ, содержат нравственно ценную информацию (об интересных людях). Структура у них одинакова: четыре абзаца, 300-350 слов. Соблюдайте во время чтения ударения, поставленные в тексте. Они там будут обязательно, поэтому будьте внимательны и не игнорируйте эти значки. Помните: одна орфоэпическая ошибка — и вы сразу теряете балл. И повторите склонение числительных. Они есть в каждом тексте , и это самое «ошибкоопасное» место (не «к четыреста» а «к четыремстам»).

***Задание № 2: пересказ***

Главное — запишите в бланк (его вам выдадут на экзамене) ключевые слова абзацев. И все получится! За две минуты, которые даны на подготовку, сделать это вполне возможно. Не теряйте первое предложение. Опирайтесь на бланк с записями при ответе, запишите в него всё, что сможете. Но, конечно, не нужно переписывать весь текст. На это и времени не хватит, и пересказ не получится.

Две минуты прошли — текст забирают, остаются только записи. Поэтому чем больше ключевых слов — тем лучше.

***Задание № 3: монолог***

В помощь ребятам дается три варианта: описать, рассказать и порассуждать. Помните — описать проще всего. Вы должны привести 10 фраз по теме приведенной фотографии. Вопросы-помощники вы найдете под текстом задания.

Если дело совсем плохо, вам окажет помощь собе седник. Он направит вас на правильные 10 фраз. Экзаменатор-собеседник является в этом задании именно помощником, но вы должны внимательно его слушать и не отвечать просто «да» и «нет».

***Задание № 4: диалог***

Это диалог по теме предыдущего высказывания. Главное — отвечать не как в «Ералаше»: «да», «э-э-э», «м-м-м», «нет». Старайтесь начать с самого вопроса (он у вас написан) — и необходимое количество баллов вы обязательно наберете!



## Минем ялгышым – минем язмышым

Без еш кына башта эшләп куябыз да, аннары гына кылган гамәлләребез, әйткән сүзләребез хакында уйлана башлыйбыз. Гаепне аңлап, гафу сорау, һичшиксез, кирәк һәм тиешле, әмма шул хаталарны эшләгән минутта кеше күңелләрендә тирән эз калдырабыз бит. Кайвакыт ул эзләр бер дә бетәр кебек түгел. Ә алар безнең күңелләрдә, безнең язмышларда мәңгелек тап булып калачак. Ак тап булса, димәк, уңышлы хәл ителгән, ә кара тап безгә шул ялгыш турында һәрчак искә төшереп сыкрап торчак бит...
Бу хәлгә инде берничә ел үтте. Ул вакытта кылганнарым турында әллә ни уйламый торган идем. Тик менә вакытлар узу белән үземнең шул чакта ни дәрәҗәдә дөрес эшләмәгәнемә төшенә барам. Бу уйлар мине кат-кат тирән хатирәләргә чумарга һәм кешеләр алдында кызарырга мәҗбүр итә.
Берничә ел элек, мин әле җиденче сыйныф укучысы булган вакытта, җәйге эссе көннәрнең берсендә дуслар белән шәһәребездә урнашкан пляжга барырга сөйләштек. Сөйләшелгән вакытта өч дус очраштык та, су буена юл тоттык. Барабыз (җәяү барырга күңеллерәк булыр дип хәл иттек), көлешәбез, этешәбез, ниндидер юк-бар турында сөйләшәбез. Ничек барып җиткәнебезне сизми дә калдык. Су буенда кызынып яткан вакыт. Коенабыз да кызынабыз. Дөнья рәхәте. Бервакыт Илдус сикереп торды да:

-Нишләп монда моңаеп утырабыз соң әле! Күңел ачасы килә минем.

-Син нәрсә турында сөйлисең? – дидем мин аңа аңышмыйча.

-Без бит инде җиткән егетләр. Спиртлы эчемлекләр кулланырга вакыт җитте. Бөтен таныш-белешләрем инде шуның белән мавыга, ә минем кабып караганым да юк.

-Безгә аны кем бирсен, акчабыз да юк, - дип өстәде Шамил.

-Табабыз аны. Мин үземнең җыйган акчамнан алып килә алам, - диде Илдус бер дә сүзен бирешергә теләмичә.
-Белмим, минем алай җыйган акчам юк ул, - ди Шамил аптырап.
-Минеке дә, - дидем мин.
-Ярар, аптырамагыз, күпме булса да табарбыз. Хәзер өйгә кайтыйк, таба алганча акча эзлик. Аннары кибет янында очрашырбыз.
-Белмим, барып чыгармы бу эшебез, - икеләндем мин.
-Син нәрсә, куркасың әллә? – дип көлеп куйды Илдус, - Бигрәк куркак икәнсез! – өстәп куйды.

-Минме? Кирәк булса, күпме кирәк, шуның хәтле акча таба алам мин! – дип киерендем.

-Мин дә таба алам! – өстәп куйды Шамил.
-Менә бу егетләрчә! – дип сөенде Илдус, үзенең теләгәненең чынга ашуын күреп,
- Бүген без чын егетләр булачакбыз, менә күрерсез, - диде Илдус серле елмаеп.
Шулай хәл иттек тә. Кичкә таба, сәгать дүртләрдә Илсурның йортлары янында җыелышырга сүз бирештек. Менә мин ашыга-ашыга өйгә кайтып барам. Йөрәк дөбер-шатыр кага, менә-менә күкрәгемнән чыгып китәр шикелле. Аягым җиргә тими дә шикелле.
Хәзер өйгә кайтып җитәм. Бер-ике тукталышны гына үтәсе калды. Бер мәлне, үзем дәсизмәстән, туктылып калдым. Минем карашымны ашамлыклар кибете янында йөгереп йөрүче эт җәлеп итте. Ана эт. Ул үзенең кечкенә балалары янында бөтерелеп йөри иде. Берсен чистарта, икенчесен урынына алып куя, өченчесен арт ягыннан этә-төртә тартма йортларына кертеп яткыра. Һәм менә хәзер ул үзе чистарынган, тамаклары тук балалары янына кереп ята. Тегендә-монда йөрүче кешеләр үзләренең кулларындагы теләсә нәрсәләре белән бәрелмәсен, төртеп интектермәсеннәр, балалары тыныч йокласын дип, үзе кибет залы ягыннан ята, ә бәләкәчләре әниләренең җылы эчләренә сыенып йокыга киткән инде.
Бу күренеш минем 4-5 минут вакытымны алды. Әмма ни өчен икәнен аңлый алмадым.
Кинәт кенә үземә йөкләнгән зур вазыйфаны искә төшердем. Миңа бит акча табып тизрәк егетләр янына чабасым бар. Миннән берничә метр ераклыкта гына беркайгысыз йоклап ятучы этләр гаиләсенә карашымны ташладым да юлымны дәвам иттем.
Өйгә кайтып җиттем. Әни аш бүлмәсендә нидер пешеренеп йөри иде.



Мин исәнләшкәндәй булдым да тизрәк үземнең бүлмәмә кереп тайдым. Ә башымда хаман бер уй. Кайдан акча алырга соң? Әнидән сорап булмый, алдашырга туры киләчәк. Йөз төрле сорау бирәчәк. Аннан соң әни - ул бик үткер кеше, ялганны тиз танып алачак. Ә ялганлаган өчен тагын әтидән дә эләгәчәк. Юк, сорарга ярамый. Нишләргә соң? Бу сорау минем баш өстемдә кылыч шикелле селкенеп торды. Бер яктан, әнине алдау бер дә яхшы түгел, икенче яктан, егетләр көтеп тора, алар белән сүз куешылган.
Шулай кая барып бәрелергә белмичә йөргәндә, күзем залда диванда ятучы кара сумкага төште. Бу әнинең сумкасы иде. Күрәсең, нидер эзләгән дә шунда диванда калдырып киткән. Аяклар үзләреннән-үзләре залга алып бардылар. Әкрен генә әнинең сумкасы янына утырдым. Менә аның кызыл кошелегы. Шуннан алырга кирәк акчаны, бетте-китте. Ул аны сизмәячәк, мин бит күп алмыйм. Куллар сумка эченә тартылды. Юк, бу дөрес түгел. Әнидән сорамыйча, ниндидер бер карак шикелле үз әниемнең эшләп алынган акчасын алсам, кем булам соң мин?! Шып туктап калдым. Бер кулым сумка эчендә кошелек өстендә эленеп калды. Мин икеләнеп торган арада, кемдер ишеккә шалтыратты. Әни ишекне ачты да мине чакырды. Илдус килгән икән. Барырга кирәк. Мин үзем дә сизмәстән, кошелектан 500 сум акчаны тартып чыгардым да Илдус янына чыгарга ашыктым. Әни аның белән гадәттәгечә елмаеп сөйләшеп тора иде. Мин исә әни ягына карамыйча, башымны иеп, тизрәк чыгып китү юлын карадым.
Илдус белән кош тоткандай подъезддан ничек чыгып киткәнебезме сизми дә калдык. Ул миңа сораулы карашын ташлады, ә мин башымны гына идем дә бер-березне аңлашып очрашу урынына ашыктык.
Без сөйләшенгән урында очраштык. Егетләр дә өйләреннән табыш белән килгәннәр. Бөтен булган акчаны уртага җыеп салдык та кемне җибәрергә микән дип уйга баттык. Безнең беребезгә дә 18 яшь юк, димәк, сатмаячаклар. Ялагайланып та булмый. Хәзер моның белән бик каты. Бер сатучының да яше җитмәгәннәргә спиртлы эчемлек сатып тотыласы килми, бәләсеннән баш-аяк. Шуларны сөйләшеп торган арада, бәхетебезгә каршы, берничә ел мәктәпне тәмамлап чыккан егетне – Владны күреп алдык. Нәкъ безнең турыдан укырга барып ятуы икән. Эй, шатлануларыбызны күрсәгез. Алтын таптыкмени!
Влад икеләнеп тормады. Әше өчен ике пачка тәмәке сорады. Без инде ризалаштык, каршы торырга чара юк. Җибәрдек моны кибеткә. Владның килүен зур тынлыкта көтеп утырдык. Менә аның шәүләсе күренде. Унбиш минут вакыт үткән микән, килеп җитте бу. Алган. Безгә аракы пакетын тоттырды да, без аңлап җиткергәнче, юкка да чыкты.
Ә без инде тизрәк табышыбызны култык астына кыстырып үзебезнең базага юл тоттык. База дип без берничә ел элек ташландык хәлενә төшкән кафега әйтә идек. Буш вакыт булып очрашканда шунда җыелыштык. Салкыннан, яңгырдан, эсседә дә саклану урыны булып китте. Беркем комачауламый, эзләп таба алмый. Рәхәт бит.
Без үзебез белгән юл белән базага барып чыктык. Әкрен генә менеп җиттек, әллә кайлардан табып, кул астындагы материаллардан җыелган өстәлгә пакетны бушата башладык.
Бер, ике, өч... Өч бутылка бар икән бит. Әй-һәй, шәп булган. Әз-мәс капкаларга да алырга онытмаган. Менә бәйрәм итәбез икән бүген!
Шулай бер-бер артлы стаканнар тула торды, ә без аларны әкренләп бушата тордык. Шундый җиңеллек, рәхәтлек җитте. Әллә ниләр сөйләшеп, юк-барга көлешеп утырганыбызны, телефон исемлегендә очраткан бер кеше номерын җыеп, аларга да әллә нәрсәләр сөйләп бетергәнбез. Күпме вакыт үткәнен тәгаен әйтә алмыйм. Илдус тәмәке тартып җибәрде. Ә без шешәне бушатуны дәвам иттек. Бер мәлне күз алларында бар нәрсә йөзеп йөри башлады. Кайдандыр төтен чыга. Илдус тартамы соң? Тик төтен көчәйгәннән-көчәя бара. Һава җитми башлады. Тышка чыгып саф һава сулап керергә кирәк дип урамга таба атладым. Әмма аякка басуым булды, аяклар мамыктай булды, йөрү түгел, юньләп басып тора да алмыйм. Тизрәк чыгып китәргә кирәк. Сулышларым кысыла башлады. Абына-сөртенә көч-хәл белән урамга чыга алдым. Күзләрем ниндидер шәүләләрне генә аера ала, башка берни күрми. Урамга чыгу белән тирән итеп сулыш алдым. Саф һава агымы бөтен тәнемнән үтеп чыккандай итте. Рәхәт булып китте. Шулай да күзләр күрми иде әле. Без утырган урыннан багана-багана төтен чыкканын гына чамаладым. Әллә кайдан кычкырган тавышлар, сирена үкерүе ишетелде. Күз алдында бар да оча, Илдус, Шамил көлеп йөриләр – әллә ниләр күрдем. Шуннан төгәл нәрсә булганын әйтә алмыйм. Бар да караңгылыкка чумды.

Мин хастаханәдә уянып киттем. Ишек янында әни белән полиция хезмәткәре сөйләшеп торалар. Әни минем аңыма килгәнемне күреп алды да йөгереп яныма килеп утырды. Хәлләремне сорашты. Мин әкрен генә башымны селкеп куям. Хәлемдә озак булмадым, тагын йокыга киттем.

Бер-ике көннән минем белән сөйләшергә, хәтемдә калганнарны язып алырга дип полиция хезмәткәре килде. Минем янга утырды да бер-бер артлы булган хәл турында сораша башлады. Үзе сорый, үзе сәерсенеп кенә карап куя, ышанып та бетмәгән кебек була. Мин аңа күпне сөйли алмадым, чөнки хәтерләми идем. Барысы да шул томанга төренеп калды. Хәтеремдә өзек-өзек булып калган хатирәләрне бәян иттем. Шуларны тыңлап һәм язып барган полиция хезмәткәре соңыннан миңа:
-Син башка берни дә хәтерләмисеңме? – дип өстәде.

-Юк, бар хәтерләгәнемне әйтеп бирдем, - дидем мин.

-Алайса... Сиңа Мансур искиткеч уңыш елмайган. Өчегез арасыннан син генә исән калдың бит. Вакытында чыгып китәргә өлгергәнсең. Шамил чыгарга тырышкан, тик өстенә янган түшәм кисәге ишелгән. Хәзер комада, аңына килүе икеле диләр табиблар, - дип сөйләде таныш түгел абый. Аңа сөйләве авыр иде, күренеп тора. Ә мин ишеткәннәрдән соң Илдус турында сорарга куркып яткан арада, абый дәвам итте:
-Ә менә өченче дустыгыз, Илдус... Янгынны сүндергәннән соң аның янып беткән тәнен генә чыгара алдык. Ул ташландык кафега янар өчен күп кирәкмәгән икән.
Кызганычка каршы, янгын сүндерү машинасы юл бирми басып торган машиналарын да әйтер идем... Син чыннан да бәхетле йолдыз астында тугансың, моны истә тотып яшә.

Ничек түзгәнмендер, әмма полиция хезмәткәре чыгып китү белән үкереп елый башладым. Күздән яшьләр чишмәдәй бертуктаусыз ага да ага. Күңелемдә әллә нинди хисләр кушылмасы буранны туза. Үкенү дә, сызлану да, оят та... Кеше күзенә ничек карарга? Егетләрнең әниләренә нәрсә дип әйтергә? Үзебезнең акылсыз шаярудан килеп чыккан зур кайгыны ничек аңлатырга? Гомумән, аңлатып буламы бу хәлне?

Бүлмәгә әни керде. Ул карават башына утырды да озак кына берни әйтми күземә карап торды. Сизәм: аңа да авыр. Әни берни әйтә алмады. Сүзсез утырып торды да, шулай ук тыныч кына торып чыгып та китте. Минем бер мәлгә дусларым янына китәсем килде. Мин бит хәзер бар кеше алдында җавап тотарга тиеш. Ә әйтер сүз юк...

Мин хастаханәдән чыктым. Бер җирем дә авыртмый, йөрәк кенә сызлый. Тик аны тынычландырырга бер дәва да юк шул. Илдусны мин хастаханәдән чыкканчы җирләгән иделәр. Мин бар көчемне җыеп, берничә атна узганнан соң, аның каберенә бардым. Бардым да кабере өстенә ятып еладым. Гафу үтендем. Башка сүз таба алмадым.
Көннәр үтә торды. Мәктәпкә дә йөри башладым. Миңа ярдәм күрсәтергә сыйныфташлар килеп йөрде. Алар мине үзләре белән паркка, тетрга йөрергә чакырдылар, сыйныф эшләреннән калдырмадылар. Мин йөрдем, булыштым, кушкан эшләрен башкардым. Тик тәнем белән күңелем икесе ике якта булды шикелле. Тәнем кешеләр арасында йөрсә дә, җаным әллә кайларда очып йөри бирде. Мин һәрвакыт узган хәлләр турында уйландым, дусларымны искә төшердем. Комада ятучы Шамилне, гүр иясе Илдусны уйламаган көнем калмады. Һәм һәрвакыт бу хәлне ничек булдырмыйча калдырып булыр иде дигән сорауган җавап эзләдем. Эзләдем һәм таба алмадым.

Әни һәрвакыт минем янда. Ул ачуланмый, тавышын күтәрми. Күзләремә тирән итеп карый гына. Кирәк булганда гына, үз сүзен әйтеп куя. Миңа авыр икәнне аңлый ул, артык сүз әйтергә куркa. Ә миңа, бәлки, аның ачулануы күбрәк кирәктер. Миңа аның каты итеп эндәшүе кылган хатамны төзәтергә булмаса да, әзрәк акланырга ярдәм итәр иде. Әни алдында шундый кыен. Мин бит аны алдап, акчасын урлап китеп бардым. Ә ул мине ачуланмый да. Эх, әни...
Ике елдан без 9 нчы сыйныф укучылары булып җитештек. Имтиханнарны уңышлы тапшырып бетергәч, кулга аттестат тоттырдылар. Ә мин әле хаман да тормышымның киләчәген анык кына ничек дәвам итәчәген аңламый идем. Без чыгарылыш сыйныфлары өчәү, 87 бала. Безнең барыбызны иртәнге сәгать унга актлар залына чакырдылар. Сыйныфташлар оештырган

ESPRIT. Школьная газета, январь 2021

кечкенә концерт караганнан соң, аттестатларны тапшыра башладылар. Барыбыз да аттестатлы булгач, укучыларның үзләренә сорау бирделәр.
Мин дә башкалар белән беррәттән сүз тотарга булдым. Моны мин үземнең бурычым итеп күрдем, шуңа алдан әзерләнмәсәм дә, җөмләләрем төзек чыгармы дип борчылсам да, үз сүземне әйтергә булдым:
-Дуслар... Сезне алда зур юл көтә. Бүген күпләребез башка уку йортларына китәр, һөнәрле булырга әзерләнер. Күп нәрсәгә өйрәнергә, әле күп нәрсәне аңларга кирәк булыр. Тик без инде балалар түгел. Һәр әйткән сүзебезгә, һәр кылган гамәлебезгә үзебез хуҗа. Шуңа аларны алдан нәтиҗәсен уйлап әйтергә һәм эшләргә кирәк. Бер ялгыш адым зур хәвеф-хәтәрләргә китерә ала. Бу бәла сезгә генә түгел, сезнең якыннарыгызга да зур кайгы китерә ала. Матур яшик, ялгышларны булдырмыйк.

Кичен сыйныфташлар кафега барырга җыенып чакырдылар. Юк, минем күңел ачарга бер теләгем дә юк иде. Мин өйдә калдым, соңрак паркта йөреп керергә булдым. Җәйге матур кичтә паркта йолдызлы зәңгәр күккә карап утырдым.

**Нәҗметдинова Эльмира Факил кызы ,**
**37нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

## Туган тел

Туган тел! Бу сүз һәркем өчен кадерле, газиз! Чөнки тел – тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Аңардан да көчле, татлы, назлы, ләззәтле тел бармы икән? Тел – ананың балага зур бүләге. Кешегә нәселнең, халкының асыл сыйфатларын иң әүвәл тел тәме, тел кодрәте ярдәмендә ана бирә. Туган телне белү кирәк. Чөнки туган телдә синең әби – бабаларың, әти – әниләрең, халкың сөйләшкән һәм сөйләшә. Туган телгә хөрмәтле булганда гына кеше үз иленең, төбәгенең, гаиләсенең шәҗәрәсен, тарихын аңлый ала. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – һәр кешенең изге бурычы. Минем туган телем – татар теле.
Минем өчен татар теле кадерле һәм газиз, чөнки без - татар балалары. Татарча минем телем ачылган, татарча бишек көйләре, әкиятләр тыңлап үстем. Шуның өчен дә ул безгә бик якын. Татар теле – татар халкы өчен уртак милли тел. Бу телдә доньяда бик күп кеше аңлаша, аралаша.

Көндәлек тормышта без еш кына үзебез сөйләшә торган телне яки телләрне табигый бернәрсә итеп кабул итәбез. Гаять зур әһәмияткә ия телебез тормыш – көнкүреше безнең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Туган тел беренче мәртәбә әйләнә – тирә мөхитен танып белергә һәм киңрәк планда дуслар, мәктәп белән аралашуда ярдәм итә торган тел ул.

Әйе, ана теле бер була. Ул безгә әнкәебезнең күкрәк сөте аша керә. Балага иң якын кеше - аның әнисе. Беренче сүзләрне дә ул анадан ишетә. Баланың беренче сүзе дә “әннә”. Һәр халык үз телен яратып “Ана теле” дип атый.

Мин татар баласы булып тууыма бик тә, бик тә сөенәм. “Әнием”, “әтием” дип татар телендә иң кадерле кешеләремә дәшә алуым белән горурланам. Әйе, әти – әнигә ярату хисен, бары тик, туган телендә генә җиткереп була. Дәү әнием миңа: “Бәбкәм, беркайчан да үз телеңне онытма, туган телеңне балаларыңа да өйрәтерсең! “- ди.

Кызганычка каршы, күп кенә гаиләләр балалары белән урыс телендә аралашалар, ә бит алар, әти- әниләр, үзара татар телендә сөйләшәләр. Хәтта дәү әти һәм дәү әниләр дә “вата – җимерә” оныклары белән урыс телендә сөйләшергә тырышалар. Мондый гаиләләр минем дусларым арасында да барлар. Минемчә, алар үз телебездә сөйләшсәләр дөресрәк булыр иде дип уйлыйм, чөнки күп телләр белү ул кешене бизи.

Татар теле – Тукай теле. Аның шигырьләрендә туган телне ярату, туган илгә булган мәхәббәт белән үрелеп килә. Шуңа күрәдә туган телне ярату ватанга тугрылыкка, ата – ананы яратуга, хөрмәт итүгә тиң. Татар телендә бик күп китаплар, телевидениедә бик күп тапшырулар алып барыла. Татар телендәге мультфильмнарны да бик яратып карыйбыз.

Безнең төп бурычыбыз - үз халкыбызның мәдәниятен, гореф – гадәтләрен, халкыбызның тарихын хөрмәт итәргә өйрәнергә, үз ана телендә сөйләшергә тиешбез. Халыкның рухи байлыгы бервакытта да саекмасын, кимемәсен, милләт үткәнен хөрмәт итсен кеше үзенең туган җирен, туган телен онытмасын иде дигән теләктә калам.

**Хисамиева Зәлинә, 10а сыйныфы укучысы**